ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _______ 20___ ел № ________

**Эшкуарлык, инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп һәм прокуратураның 2021 елның 13 декабрендәге 02-08-02-2021 номерлы протесты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. 2017 елның 5 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган Эшкуарлык, инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибендә 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Муниципаль актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү вәкаләтле орган - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле бюджетының эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р. Р. Нотфуллин